**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**от 28.04.2022**

**КАРАР**
**№ 447**

## 16:16:080313:592 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссиянең 2022 елның 27 апрелендәге бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гарипов Рөстәм Кәрим улы һәм Гейко Наталья Ивановнаның уртак өлешле милкендәге 16:16:080313:592 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» төреннән «кибет, иҗтимагый туклану, көнкүреш хезмәт күрсәтү» төренә үзгәртергә.
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» на: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы А.М. Хөснетдиновка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов